**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ШАХМАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШАХМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ул. Центральная, д.45Б,
с. Шахмайкино,423183

Үзәк урам, 45Б
Шахмай авылы,423183

тел.: (8-84348) 3-84-96, факс: (8-84348) 3-84-46, Shah.Nsm@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның 25 декабре № 17

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге торак пунктларында үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы № 33-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Шахмай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге башкарма комитеты карар итте:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге торак пунктларында гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге башкарма комитетының 26.12.2022 № 14 «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге торак пунктларында гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында» карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында: https://pravo.tatarstan.ru һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https:/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Н.М. Илалова

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге башкарма комитеты карарына кушымта
2025 елның 25 декабре № 17

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең торак пунктларында гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Әлеге тәртип Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге торак пунктларында гражданнардан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Шахмай авыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән, гражданнар җыенында (җирле референдумда) катнашуларына һәм тавыш биргәндә алар тарафыннан нинди җавап бирелүгә карамастан, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салымын кертү турында карар кабул ителгәннән соң киләсе елның 31 мартына кадәр башкарыла.

3. Үзара салым буенча бер тапкыр түләүдән азат ителә торган затларның категорияләре гражданнар җыенында билгеләнә һәм кабул ителә.

4. Нигезле сәбәпләр (авыру, озак командировка, отпуск) аркасында бер түли алмаган түләүчеләр Шахмай авыл җирлеге башкарма комитетына бер тапкыр түләүне кичектерү турында гариза белән мөрәҗәгать итә алалар. Кичектерү өч айга бирелә.

5. Бер тапкыр түләнә торган түләү турында хәбәр итү бланкы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгару юлы белән гражданнарга җиткерелә: https://novosheshminsk.tatarstan.ru, шулай ук кул куеп тапшыру яки почта элемтәсе аша җибәрү юлы белән (кушымта итеп бирелә).

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр түләүнең тулы яки киметелгән күләме, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Шахмай авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә.

7. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар кушуы буенча исәп-хисапны башкарырга, почта күчерүләрен башкарырга хокуклы оешмалар (исәп-хисап оешмалары) аша, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Шахмай авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша https://uslugi.tatarstan.ru сылтама буенча акча күчерү юлы белән башкарыла..

8. Түләү фактын приход касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслый торган башка документлар раслый.

9. Гражданнарның үзара салым акчалары әлеге тәртиптә билгеләнгән срокта түләнмәгән очракта, законда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге торак пунктларында гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибенә кушымта

БЕЛДЕРМӘ № ___

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү

Түләүче Ф.И.А.и.________________________________________________________
Адресы:_______________________________________________________________
_______________________________________________________нигезендә
Сезгә ________ га кадәр _________________________ чараларны тормышка ашыру өчен ______________ сум бер тапкыр түләү түләргә кирәк,
түбәндәге реквизитлар буенча:_____________________________________________________

Алучы банкы:

БИК_____________________________________________________
Сч. № ___________________________________________________
Алучы Сч. № ______________________________________________
ИНН________________ КПП_________________________________
КБК _________________ ОКАТО ____________________________
Түләү билгеләмәсе ___________________________________________
Җитәкче ___________________ ________________________________________
П.У. (имза) (имза аңлатмасы)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү линиясе - - - - - - - - - - - - - - -

Белдермә (Белдерү) № __________________

Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү суммасы турында _________________ сум.

Түләүче Ф.И.А.и._________________________________________________________
Адресы: ___________________________________________________________________

Алды «__» ________________ 20__ ел. ________________________________________
(түләүче имзасы)

*Искәрмә. Хәбәр түләүчегә шәхсән тапшырылса, тармак тутырыла һәм Шахмай авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.*